РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423586, г. Нижнекамск, пр. Строителей, 12
тел./факс (8555) 41-70-00

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

423586, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
тел./факс (8555) 41-70-00

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

№ 61　　　　　　　　　　　　　　　　2022 елның 17 октябре

**Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 237-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

28 пунктның 4 пунктчасында «мәҗбүри пенсия иминияте системасында» сүзләрен «мәҗбүри пенсия иминияте һәм мәҗбүри социаль иминият системаларында» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фонды» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы　　　　　　　　Р.Х. Муллин

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН